| | | |
|---|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>БУИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БУА<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«05» июнь 2018 ел Буа шәһ. № 158/ИК-п

2018 елда гражданнар keременең
һәм салым алынырга тиешле милек бәясенең
максималь күләмен раслау турында

06.10.2003 елгы 131-ФЗ номерлы «РФ җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, 16 марта 2015 елның 16 мартындагы 3-ЗРТ номерлы «Социаль кулланылыштагы торак фондның торак биналарын найм килешүе буенча гражданнарга торак биналар бирү хокукын тормышка ашыру турында” ТР Законы нигезендә, ТР Буа муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР ЧЫГАРА:**

1. 2018 елда гражданнарның мохтаҗ булуын тану турында карар кабул итү өчен максималь күләмне билгеләргә:

1.1. гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче гражданин хуҗа булган һәм салым алынырга тиешле милек бәясенең максималь күләме:

1.1.1. ялгыз яшәүче гражданин өчен – 1 233 474,00 сум;

1.1.2. ике кешедән торган гаилә өчен – 1 569 876,00 сум;

1.1.3. өч кешедән торган гаилә өчен – 2 018 412,00 сум;

1.1.4. дүрт кешедән торган гаилә өчен – 2 691 216,00 сум;

1.1.5. биш кешедән торган гаилә өчен – 3 364 020,00 сум;

1.1.6. алты кешедән торган гаилә өчен – 4 036 824,0 сум;

1.1.7. җиде кешедән торган гаилә өчен – 4 709 628,0 сум;

1.2. гражданин гаиләсенең һәр әгъзасына туры килгән уртача айлык гомуми керемнең максималь күләме түбәндәгечә билгеләнә:

1.2.1. ялгыз яшәүче гражданин өчен – 14 853,88 сум;

1.2.2. ике кешедән торган гаилә өчен – 9 452,47 сум;

1.2.3. өч һәм күбрәк кешедән торган гаилә өчен – 8 102,11 сум.

1.3. Торак биналарга мохтаҗ булганнарны исәпкә куйганда, әлеге карарның 1.1 һәм 1.2 пункт асларында күрсәтелгән максималь күләмнәрдән файдаланырга.

2. Әлеге Карар рәсми рәвештә бастырылган көннән алып үз көченә керә һәм http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча ТР хокукый мәгълүмат Рәсми порталының рәсми сайтында, шулай ук http://buinsk.tatarstan.ru. адресы буенча Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә ТР муниципаль берәмлекләр Порталында урнаштырылачак.

3. Әлеге карарның үтәлүен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Буа муниципаль районы
Башкарма комитеты Җитәкчесе Р.Р. Камәртдинов